**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Ш. Марджани
дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы.,
6 нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 апрель 2026 ел. № 126

**Әтнә район башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында " 23.12.2023 елгы 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, гамәлдәге кануннарга туры китерү максатыннан Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә район башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

06.08.2021 №251 «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

06.08.2021 №254 «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

06.08.2021 №255 «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

06.08.2021 №260 «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

22.12.2021 №558 «Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының 06.08.2021 № 251 карары белән расланган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»;

13.04.2022 №127 «Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесенең 06.08.2021 № 254 карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында»;

25.04.2022 №138 «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов